ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 17 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $13^2$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$13^2$) федераль дәүләт урман комплексы мәгълүмат системасына белешмәләр кертү һәм күрсәтелгән системада документлар урнаштыру;»;

2) $13^9$ пунктта «(моңа урман орлыклары буенча районлаштыру, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын булдыру һәм урманнарны торгызуны дәүләт тарафыннан мониторинглау керми)» сүзләрен «(моңа урманнарны торгызуны дәүләт тарафыннан мониторинглау керми)» сүзләренә алмаштырырга, «, урман орлыкчылыгын (моңа урман орлыклары буенча районлаштыру, федераль урман үсемлекләре орлыклары фондын булдыру, куллану һәм саклау керми)» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $13^{12}$ пункт өстәргә:

«$13^{12}$) Татарстан Республикасы урман үсемлекләре орлыкларының иминият фондын булдыру, куллану һәм саклау;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 һәм 3 пунктлары 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 23 июль
№ 51-ТРЗ